“Каралды”
Методик берләшмә җитәкчесе:
________ Гареева А.Х.
Беркетмә №__,
“31” __08__ 2023 ел

“Килешенде”
Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: ________
Гараева С.Р.
«31» __08__ 2023 ел

“Расланды”
Мәктәп директоры: ________
Гайнуллин З.А.
Приказ № __
«31» __08__ 2023 ел

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
МБГББУ “Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе”

I квалификацион категорияле укытучы
Гареева Лилия Бахрам кызының

**Гомуми мәдәни** юнәлештәге
“Сөекле туган телем...”
дәрестән тыш эшчәнлегенең
эш программасы

Педагогик киңәшмә утырышында каралды.
Беркетмә №1, 31 августа, 2023 ел.

2023 ел

| “Каралды” | “Килешенде” | “Расланды” |
| --- | --- | --- |
| Методик берләшмә җитәкчесе: __________ Гареева А.Х. | Уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары: ___________ Гараева С.Р. | Мәктәп директоры: _________ Гайнуллин З.А. |
| Беркетмә №__, “___” ___________ 2023 ел | «____»____________2023 ел | Приказ № «__» ___________ 2023 ел |

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы
МБГББУ “Олы Кариле урта гомуми белем бирү мәктәбе”

I квалификацион категорияле укытучы
Гареева Лилия Бахрам кызының

**Гомуми мәдәни** юнәлештәге
“Сөекле туган телем...”
дәрестән тыш эшчәнлегенең
эш программасы

Педагогик киңәшмә утырышында каралды.
Беркетмә №__, ________________, 2023 ел.

2023 ел

Башлангыч сыйныфлар өчен “Сөекле туган телем...” дәрестән тыш эш программасы татар халык авыз иҗаты төрләрен,аларның яшь үзенчәлегенә туры килерлек үрнәкләрен үз эченә ала. Бу темалар балаларның телне үзләштерү дәрәҗәсенә туры килерлек итеп, метапредмет бәйләнешләрне, уку процессындагы логик эзлеклелекне искә алып сайланган һәм сәгатьләргә бүленгән.

Халык авыз иҗаты баланы сәнгать дөньясына җәлеп итү, халыкның традицияләре белән таныштыру өчен иң кулай материал булып кына калмый, образлы фикерләү үстерү, эстетик кыйммәтләргә уңай караш тудыруда да зур ярдәм итә. Туган халкы авыз иҗаты әсәрләре баланы бишектән алып озатып килсә, күрше халык иҗаты үрнәкләре аңа дөньяны танып белергә ,толерант шәхес булып формалашырга зур ярдәм итә.

Белем бирү процессын халыкның күпьеллык традицияләренә нигезләнеп кору бүгенге көндә иң актуаль мәсьәләләрдән санала,чөнки халык җырлары, әкиятләре, уеннары, мәкаль һәм әйтемнәре баланың рухи-эстетик үсешендә төп рольне уйный , тормышны аңлауда һәм аңа яраклашуда зур ярдәм итә.

**Программаның максаты**: халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәкләрен өйрәнеп , укучыларның интеллект дәрәҗәсен үстерү, тормышка яраклашкан (социальләшкән) шәхес тәрбияләү.

Бу максатка бәйле рәвештә түбәндәге **бурычлар** куелды:

- татар халык авыз иҗаты тарихы, жанрлары, халыкның милли киемнәре белән танышу

- халык традицияләренә, костюмына, милли мирасына кызыксыну хисләре, хөрмәт уяту.

- балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.

**1 бүлек.**
**Курсны үзләштерүнең планлаштырыла торган нәтиҗәләре.**
**Шәхескә юнәлтелгән УУГ (универсаль уку гамәлләре):**

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- халык авызтекстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.
- биремнәр системасында ориентлашырга өйрәнү.

- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- үз фикереңне әйтә белү.
- кешеләргә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру.

**Танып-белү универсаль уку гамәлләре:**

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.
- укучыларның бер-берсе белән туган телдә аралашуы;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшләргә өйрәнү;
- фәнни-тикшеренү эшләре алып бару;
- татар халкының гореф-гадәтен дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда куллану;
- үзләренең иҗади эшләрен яклау һәм газета – журналларда бастыру;

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хисслелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.
- партадашы белән эшли, эшләрне үзенә һәм иптәшенә куша, үзенә тапшырылган эшне башкара, үзбәя бирә, иптәше эшләгән эшнең нәтиҗәсе белән кызыксына белергә;
- әсәрләрне чагыштырып, нәтиҗә ясарга;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
- сорауларга җавапны төрлечә биреп булуын аңларга;
- текст өлкәсендә эшләп, җавапларны табарга, дөрес җавап билгеләп, фикерен дәлилләргә.
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;

- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү

**Предмет нәтиҗәләре:**

*Тыңлап аңлау:*

- халык акылы , тормыш яме, яшәү көче чыганагы булган халык авыз иҗаты турында мәгълүматлы булу;
- төрле жанрдагы халык авыз иҗаты әсәрләрен тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;
- сүзләрне, җөмләләрне аңлап кабул итә белү;
- тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;
- зур булмаган халык авыз иҗаты әсәрләрен, тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;
- сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.
- әсәрләрнең жанрын аера белү.
- әкият, легендаларның эчтәлеген сөйли белү.

*Диалогик сөйләм:*

- сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;
- парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;
- халык уеннарын өйрәнү;
- татар телендә кечкенә әсәрләрне сәхнәләштерү.

*Монологик сөйләм:*

- халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәгендә әкиятләр, табышмаклар һ.б. төзи алу һәм аның эчтәлеген сөйли белү;
- конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;
- сөйләмдә мәкаль-әйтемнәр кулланырга өйрәнү.

**2 бүлек. Курсның эчтәлеге, оештыру формалары, эшчәнлекнең төп төрләре.**

“Сөекле туган телем” дәрестән тыш эшчәнлек программасы һәр елны атнага 1 сәгать вакыт белән 136 сәгатькә исәпләнгән. 1 ел- 34 сәг. (34 уку атнасы); 2, 3 һәм 4 елларда - 34 әр сәг. (34 уку атнасы);

## Программаның эчтәлеге

| № | Тема | 1 ел | 2 ел | 3 ел | 4 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Балалар фольклоры. | 8 | 5 | 6 | 6 |
| 2. | Татар халык әкиятләре. | 5 | 5 | 5 | 4 |
| 3. | Мәзәкләр.. | 1 | 2 | 2 | 2 |
| 4. | Татар халык җырлары. | 3 | 3 | 3 | 3 |
| 5. | Татар халык бәйрәмнәре. | 2 | 3 | 2 | 2 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 6. | Татар исемнәре. | 2 | 3 | 2 | 3 |
| 7. | Милли киемнәр | 2 | 3 | 3 | 4 |
| 8. | Өстәл әдәбе. | 5 | 3 | 4 | 4 |
| 9. | Татар телендә нәшер ителүче балалар журналлары. | 2 | 3 | 2 | 2 |
| 10 | Иҗади эшләргә корылган дәресләр | 4 | 4 | 5 | 4 |
| | | 34 | 34 | 34 | 34 |

1. **Балалар фольклоры.**

Балалар фольклоры турында төшенчә бирү, китаплар белән таныштыру. Тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар, хәрәкәтле такмаклар,мәкальләр җыю. (Хәрәкәтле такмакларның максаты – авазларны дөрес әйтергә өйрәтү, хәрәкәтләрне такмаклау гамәле белән координацияләү, хәрәкәтләр сайлаганда балаларга иҗат өчен мөмкинлекләр бирү, оялу, киеренкелек хисеннән котылу өчен шартлар тудыру).

2. **Татар халык әкиятләре.**

Татар халык әкиятләре белән танышу. Татар халкының хайваннар турындагы әкиятләрендә төп герой, аның характеры. Бик борынгы әкиятләр, борынгы әкиятләр, әкияти вакыйгалар. Тылсымлы дөньядагы предметлар, әкияти төсләр, тылсымлы булышчылар. Тылсымлы әкият геройлары. Тылсым дөньясы, булышчылар, тылсымлы предметлар, тылсымлы саннар (3, 7, 13, 40). Әкиятләрдә юмор хисе. Алдавыч әкиятләр. Әкият сайлап алып сәхнәләштерү яки курчак театры оештыру.

3. **Мәзәкләр**. Татарча мәзәкләр уку. Иң кызык мәзәк сөйләүчегә конкурс. Хуҗа Насретдин белән таныштыру.

4. **Татар халык җырлары**. Татар халык җырлары белән танышу. Уен-бию җырлары.Борынгы татар халык җырлары. Татар халык җырларын башкаручы артистлар. Кызлар исеменә багышланган җырлар.

**5.Татар халык бәйрәмнәре..**

Татар халык бәйрәмнәре турында мәгълүмат бирү. “Сөмбелә”, “Нәүрүз”, “Сабантуй” бәйрәмнәре. Бәйрәмнәр үткәрү өчен әзерлек эшләре алып бару. Гаилә бәйрәмнәре. Татар халкының дини бәйрәмнәре һәм йолалары: “Аулак өй”, “Каз өмәсе”

**6.Татар исемнәре.**

Кайбер татар исемнәре белән танышу. Мәгънәләрен билгеләү. Исем кушу йоласы. Шәҗәрә төзү. Тарих һәм әдәбият укытучылары белән берлектә эшләү. Гаилә шәҗәрәсе (поект).

**7.Милли киемнәр.**

Татар халкының милли киемнәре белән таныштыру. Кием әдәпләре турында әңгәмә оештыру. Проект “Милли киемебезне бизәүче элементлар”.

**8.Өстәл әдәбе.**

Татар халык ашлары турында әңгәмә оештыру. Проект “Татар халык ашлары”.Табын әдәпләре. Кунак чакыру, кунакка бару темасына диалоглар. Проект “Минем әнием – татар халык ашлары остасы! “

**9.Татар телендә нәшер ителүче балалар журналлары.**

“Сабыйга”, “Салават күпере” журналлары, “Сабантуй” газеталары белән таныштыру, мөхәррирләр белән очрашу, иҗади эшләрне бастыру.

**10.Иҗади эшләргә корылган дәресләр** бәйрәмнәр үткәрүгә, яисә эзләнү, фәнни-тикшеренү эшен оештыруга бирелә.

**Оештыру формалары, эшчәнлекнең төп төрләре**

Занятиеләрне уңышлы үткәрү өчен төрле формалар кулланыла:

- уеннар;
- китапханәдә өстәмә әдәбият белән эш;
- әңгәмә;
- экскурсияләр (мөмкинлек буенча);
- кичәләр, бәйрәмнәр;
- әкиятләрне, мәзәкләрне сәхнәләштерү;
- кечкенә хикәяләр, әкиятләр, мәзәкләр төзү;
- ата – аналар һәм әби – бабайлар белән берлектә иҗади биремнәр үтәү.

***Эшчәнлек төрләре:***

- укучылар белән әңгәмәләр;
- иртәләр, викториналар, конкурс, төрле ярышлар
- рольле, хәрәкәтле , халкыбызның җырлы – биюле уеннар;
- сәхнәләштерелгән әкиятләр;
- китап укучылар конференциясе;
- бәйрәмнәр;
- өлкән буын кешеләре белән очрашулар.
- иҗади биремнәр үтәү: альбомга материаллар туплау, төрле темаларга зур булмаган телдән журнал әзерләү, газета чыгару
- махсус әдәбият өйрәнү, музей материаллары белән танышу, Балалар өчен булган газета –журнал материаллары белән танышу
- эзләнү-тикшеренү эшен оештыру (материал җыю)

**3 бүлек**

**1 нче ел**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Кереш дәрес. | 1 |
| 2 | Табышмаклар | 1 |
| 3 | Тизәйткечләр | 1 |
| 4 | Әйтешләр. Әйтемнәр. | 1 |
| 5 | Мәкальләр. | 1 |
| 6 | Санамышлар. | 1 |
| 7 | Сынамышлар | 1 |
| 8 | Татар халык уеннары. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 9 | Уйныйбыз да, җырлыйбыз да... | 1 |
| 10 | Тормыш-көнкүреш әкиятләре | 1 |
| 11-12 | Тылсымлы әкиятләр | 2 |
| 13 | Хайваннар турындагы әкиятләр | 1 |
| 14 | “Әкият”тә кунакта.(Казан шәһәренә читтән торып экскурсия) | 1 |
| 15 | Көлке көлә килә, арттан куа килә. | 1 |
| 16 | Татар халык җырлары. | 1 |
| 17 | Кызлар исеменә багышланган җырлар | 1 |
| 18 | Җырларга мин бик оста. | 1 |
| 19 | Татар халык бәйрәмнәре | 1 |
| 20 | Сабантуйга барабыз | 1 |
| 21 | Исемең матур, кем кушкан? | 1 |
| 22 | Минем гаиләмдәге исемнәр. | 1 |
| 23 | Милли киемнәр белән танышу | 1 |
| 24 | Милли киемнәр рәсемдә | 1 |
| 25 | Өстәл янында үз – үзеңне тоту кагыйдәләре. | 1 |
| 26 | Ашаү әдәбе. | 1 |
| 27 | Табын әзерләү серләре | 1 |
| 28-29 | Татар халык ашлары | 2 |
| 30 | Гаилә бәйрәме | 1 |
| 31 | Татар телендә нәшер ителүче журналларга күзәтү | 1 |
| 32 | “Сабантуй”да кунакта | 1 |
| 33-34 | Иҗади дәрес. | 2 |

**2 уку елы**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Хәрәкәтле такмаклар. | 1 |
| 2 | Әйтем-сүзнең бизәге. | 1 |
| 3 | Хикмәтле сүзнең бер төре – мәкаль. | 1 |
| 4 | Чагыштыру, табышмаклар. | 1 |
| 5 | Сынамышлар, санамышлар. | 1 |
| 6 | Әкиятләр безне нәрсәгә өнди? | 1 |
| 7 | Татар халык әкиятләре. Алдавычлар. | 1 |
| 8 | Әкиятләрнең төрләре. | 1 |
| 9 | Кем әкият укый белә? | 1 |
| 10 | Әкият бездә кунакта! | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 11 | Иҗади дәрес. Әкиятләр кичәсе. | 1 |
| 12 | Мәзәкләрнең кеше тормышындагы роле. | 1 |
| 13 | Мәзәк сөйлим, син тыңла! (Иң кызык мәзәк сөйләүчегә конкурс) | 1 |
| 14 | Җырсыз, моңсыз кеше яши алмый. | 1 |
| 15 | Җырлы – биюле уеннар. | 1 |
| 16 | Әбием янчыгыннан. (Борынгы татар халык җырлары) | 1 |
| 17 | Җырчы гаиләләр бәйгесе. | 1 |
| 18 | Бәйрәмнәр кирәк һәммәбезгә дә... | 1 |
| 19 | "Нәүрүз" бәйрәме кайчан үткәрелә? | 1 |
| 20 | Безнең гаиләдә бәйрәмнәр ничек үтә. | 1 |
| 21 | Исеменә күрә җисеме. | 1 |
| 22-23 | Борынгы һәм яңа исемнәр. | 2 |
| 24 | Бабамның түбәтәе, әбиемнең калфагы. | 1 |
| 25 | Төсле кәгазьдән аппликация. "Читек" | 1 |
| 26 | Заманча милли кием. | 1 |
| 27 | Мәктәп ашханәсендәге милли ризыклар. | 1 |
| 28 | Кунак ашы – кара-каршы. Табын әдәбе. | 1 |
| 29 | Проект "Минем әнием – татар халык ашлары остасы! " | 1 |
| 30 | Мин – нәни пешекче! (Иҗади дәрес) | 1 |
| 31 | Балалар журналы ничек барлыкка килә? | 1 |
| 32 | "Салават күпере" – иң кызыклы журналларның берсе! | 1 |
| 33 | Минем беренче шигырем. | 1 |
| 34 | Иҗади дәрес. | 1 |

**3 уку елы**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Балалар фольклоры нәрсә турында сөйли? | 1 |
| 2 | Синең телең баймы? | 1 |
| 3 | Тапкырга - табышмак. | 1 |
| 4 | Татар халык сынамышлары. | 1 |
| 5 | Проект "Тематик мәкальләр җыю". | 1 |
| 6 | Бәетләр. | 1 |
| 7 | Әкиятләр. Аларның төрләре. | 1 |
| 8 | Әкиятне ничек башларга һәм ничек тәмамларга? | 1 |
| 9 | Әкият язам утырып, кәгазь битен тутырып. | 1 |
| 10 | Әкиятләр уку бәйгесе. | 1 |
| 11-12 | Без – нәни артистлар! (Курчак театры әзерләү.) | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | Сүз куәте нинди була? Мәзәкләрне урынлы куллану. | 1 |
| 14 | Хуҗа Насретдин кем ул? | 1 |
| 15 | Кем катырак көлдерер? (Көлдергечләр уку бәйгесе.) | 1 |
| 16 | Җыр – кемнәрнең иҗат җимеше? | 1 |
| 17 | Татар халык җырларында кеше исемнәре. | 1 |
| 18 | Авылыбызның һәвәскәр җырчылары белән авыл клубында очрашу | 1 |
| 19 | Татар халык бәйрәмнәре. | 1 |
| 20 | Татар халкының дини бәйрәмнәре һәм йолалары. | 1 |
| 21 | Гаилә бәйрәме “Аулак өй” | 1 |
| 22 | Татар халкында исем кушу йоласы. | 1 |
| 23 | Борынгы исемнәр тарихы. | 1 |
| 24 | Проект “Милли киемебезне бизәүче элементлар”. | 1 |
| 25 | Этнография музеена экскурсия. | 1 |
| 26-27 | Курчакка милли күлмәк тегү. | 2 |
| 28 | Татар халык ашларының күптөрлелеге. | 1 |
| 29 | Кунак булсаң, тыйнак бул! | 1 |
| 30 | Кунакларны каршы алу һәм озату. | 1 |
| 31 | Күчтәнәч серләре. | 1 |
| 32 | “Ялкын” журналы - минем дустым! | 1 |
| 33 | Почта бүлегенә экскурсия. Балалар өчен иҗат ителгән газета-журналларга язылу. | 1 |
| 34 | Йомгаклау дәресе. | 1 |

**4 уку елы**

| № | Тема | Сәгать саны |
|---|---|---|
| 1 | Тизәйткеч – тел шомарткыч. | 1 |
| 2 | Эндәшләр. | 1 |
| 3 | Халык әйтсә, хак әйтә! (Мәкаль, әйтем, сынамышлар.) | 1 |
| 4 | Куен дәфтәре ясау. (Иң кызыклы табышмаклар җыелмасы.) | 1 |
| 5 | Бәетләр. | 1 |
| 6 | Такмаклар, такмазалар. | 1 |
| 7 | Әкият – минем балачак дустым! | 1 |
| 8 | Әкияттәге уңай һәм тискәре образлар. | 1 |
| 9 | “Кем күбрәк белә?” (Татар халык әкиятләре буенча уен - дәрес.) | 1 |
| 10 | Казан шәһәре курчак театрына читтән торып экскурсия. | 1 |
| 11 | Хикмәтле сүз- мәзәк. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 12 | Көлегез, көлегез, файдасы күп, белегез! | 1 |
| 13 | Моң керде күңелләргә! Татар халык җырлары. | 1 |
| 14-15 | Татар халык җырларын башкаручы артистлар. | 2 |
| 16 | Һәр халыкның үз бәйрәме. | 1 |
| 17 | “Каз өмәсе”. | 1 |
| 18 | Без бәйрәм яратабыз. Кичә. | 1 |
| 19 | Заманча исемнәр модасы. | 1 |
| 20 | Булачак баламның исеме нинди булыр һәм ни өчен? | 1 |
| 21-22 | Гаиләм шәҗәрәсе. Әби-бабаларым ни атлы булган? (Проект) | 2 |
| 23 | Татар халык киемнәрендә орнаментлар. | 1 |
| 24 | Татар халкының бизәнү әйберләре. | 1 |
| 25-26 | Мин – дизайнер! “Киләчәк буынга заманча милли кием” проектын төзү. | 2 |
| 27 | Милли музейга  читтән торып экскурсия. | 1 |
| 28 | Милли ризыкларларның төрлелеге.. | 1 |
| 29 | Милли ризыкларның файдасы һәм зарары. | 1 |
| 30-31 | “Татар халык ашлары” проектын төзү һәм яклау | 2 |
| 32 | Газета, журнал битләрендә үз мәкаләләреңне күрү өчен нишләргә кирәк? | 1 |
| 33 | Безнең иҗат җимешләребез. | 1 |
| 34 | Без нәрсәләргә өйрәндек? Йомгаклау дәресе. | 1 |